СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

31.10.2025 № 2/15

На № _______ от _______

# КАРАР

**Тукай муниципаль районы Советының 2013 елның 29 маендагы 22/9 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль район халкының түләүсез квалификацияле юридик ярдәм алу хокукын гамәлгә ашыру максатында, «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 324-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, район уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының 2013 елның 29 маендагы 22/9 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) инвалид балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, белем алу чорында бер яки ике ата-анасын югалткан затлар (төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары, төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яки) эшче һөнәрләре, хезмәткәр вазифалары буенча һөнәри әзерлек программалары буенча белем алу чорында ата-анасы яки бердәнбер ата-анасы вафат булган 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге затлар) шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләр, әгәр алар күрсәтелгән затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен котрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров